**СОВЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

02.09.2019 г. — с. Ульянково — №15

**«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2018 елның 30 апрелендәге 89 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында “.**

РФ Хөкүмәтенең "Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары нигезендә ("Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру кагыйдәләре", "Норматив хокукый актларның коррупциягә каршы экспертизасын уздыру методикасы" белән бергә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме, вазыйфаи окладларының күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карарына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының 30.04.2018 № 89 номерлы Ульянково авыл җирлеге советы тарафыннан расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9 нчы кушымтаның 1 пунктында: «мөмкин» сүзтезмәләрен, «җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе каравыннан» төшереп калдырырга; «Түләнергә» сүзен «түләнә» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башлыгы: Ф.А.Сундурова**